**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3445**
**21.05.2021**

Муниципаль контроль төрләре
исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17.1 статьясы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясының 18.2 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Муниципаль контроль төрләре исемлеген кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф. Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 21 маендагы
3445 номерлы карарына
кушымта

Муниципаль контроль төрләре
исемлеге

| № т/б | Муниципаль контроль төренең исеме | Муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләр бирелгән Башкарма комитет органнары исеме (урнашу урыны, телефон) | Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча Башкарма комитет органының вәкаләтләрен билгели торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актының, муниципаль норматив хокукый актның исеме һәм реквизитлары | Муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында муниципаль норматив хокукый актның исеме һәм реквизитлары |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Муниципаль җир контроле | Административ-техник инспекция идарәсенең җирдән файдалануны һәм яшел утыртмалар сакланышын контрольдә тоту бүлеге (Х. Туфан проспекты, 23 йорт Яр Чаллы шәһәре, (8552) 30-59-10) | Россия Федерациясе Җир кодексы; «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон; «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон; Татарстан Республикасы Җир кодексы; Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Законы; Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2015 елның 13 октябрендәге 83-ТРЗ номерлы Законы; | Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияне үтәүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 19 октябрендәге 6260 номерлы карары |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты структурасын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 34/7 номерлы карары | |
| 2. | Муниципаль торак контроле | Шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе (Х. Туфан проспекты, 23 йорт Яр Чаллы шәһәре, (8552) 30-59-52) | Россия Федерациясе Торак кодексы;<br>«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон; Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Законы;<br>Татарстан Республикасының «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Законы | Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияне үтәүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 27 мартындагы 1631 номерлы карары |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева